РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Большекармалинского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул.Центральная, 4,с.Большие Кармалы, 422830
тел. (8277)35-2-38, факс: (8277) 35-2-38
ОКПО 93065191, ОГРН 1061672018022
ИНН/КПП 1622004612/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Олы Карамалы**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Узэк урамы , 4,Олы Карамалы авылы, 422830,
тел. (8277)35-2-38, факс: (8277) 35-2-38
ОКПО 93065191, ОГРН 1061672018022
ИНН/КПП 1622004612/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«11» сентябрь 2018 ел** **№ 9**

2018 елның 6 июнендәге “2018-2035 елларга кадәр Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авылы җирлеге башкарма комитеты социаль инфраструктурасы комплекслы Программасын раслау турында”гы 5 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль закон нигезендә, гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 29 маендагы 3 номерлы карары белән расланган 2018-2035 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) “халыкның социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең максатчан күрсәткечләре (Индикаторлары)” юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| Социаль инфраструктура объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү буенча планлаштырылган чараларның (инвестицион проектларның) кыскача | Олы Карамалы авылы мәдәният йортына капиталь ремонт – 2022 ел |

| | |
|---|---|
| тасвирламасы | |

2) 1.4 пунктының 3 абзацында “муниципаль заказны формалаштыру” сүзләрен “муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру” сүзләренә алмаштырырга, “максатчан” сүзен “дәүләт, республика, муниципаль” сүзләренә алмаштырырга;”;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый информациясенең рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Карамалы авылы
җирлеге” башкарма комитеты җитәкчесе Э. И. Бәйдамшин